Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге составына керүче
Яңавыл авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

30 ноябрь 2021 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Биектау авыл җирлеге составына керүче Яңавыл авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Яңавыл авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- Яңавыл т.п. урамнарын яктыртуны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (килешү буенча);
- Яңавыл авыллары урамнарның юл өлешен (урамнарны чистарту) кышкы чорда кардан чистарту;
- җәйге чорда Янавыл (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)торак пунктларында территорияне чабу;
- Яңавыл т. п. Киров урамы буенча урам юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу;
- Янавыл т. п. зиратында ритуаль йорт урнаштыру.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Биектау авылы, Х. Сафиуллин урамы, 4 йорт; Околоток-Яңасала авылы, Калинин урамы, 102 йорт; Чаллыбаш авылы, М. Горький урамы, 69 йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Гилазиева А.Р.

Биектау авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы: Гилазиева А.Р.